| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

11.12.2019 Казан шәһәре № 3-4/э

«ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясе тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020-2024 елларга аерым тарифлар билгеләү хакында

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы 35-ФЗ номерлы федераль законга, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Электр энергетикасында җайга салынулы бәяләр (тарифлар) өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2011 елның 29 декабрендәге 1178 номерлы карарына, Федераль тарифлар хезмәтенең "Ваклап сату (куллanучылар) базарында электр (җылылык) энергиясенә җайга салынулы тарифлар һәм бәяләр хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2004 елның 6 августындагы 20-э/2 номерлы һәм «Электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә зарури тулай табышны озак вакытлы индексацияләү методын кулланып билгеләнә торган тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2012 елның 17 февралендәге 98-э номерлы боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә, шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр 2020-2024 елларга календарь буенча бүленгән аерым тарифлар билгеләргә.

2. Үзенә карата электр энергиясе тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген дәвамлы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен, шушы карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, 2020-2024 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары билгеләргә.

3. Әлеге карарның 3 нче кушымтасына туры китереп, «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2020-2024 еллар кирәкле тулай керемен (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча) билгеләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын башкаручы Л.П.Борисова

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-4/э карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте һәм «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте челтәр оешмалары арасында үзара исәп-хисаплар ясау өчен электр энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә 2020 елның 1 гыйнварыннан 2024 елның 31 декабренә кадәр календарь буенча бүленгән аерым тарифлар

| т/с | Челтәр оешмасының аталышы | Ел | 1 гыйнвардан 30 июньгә кадәр | | | 1 июльдән 31 декабрьгә кадәр | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф | Ике ставкалы тариф | | Бер ставкалы тариф |
| | | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | | Электр челтәрләрен карап тоту ставкасы | Технологик чыгым (югалту) өчен түләү ставкасы | |
| | | | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг | сум/МВт·ай | сум/МВт·сәг | сум/кВт·сәг |
| 1 | «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 253 741,29 | 119,70 | 0,57789 | 253 741,29 | 119,70 | 0,57789 |
| | | 2021 | 257 559,81 | 119,70 | 0,58479 | 257 559,81 | 123,29 | 0,58838 |
| | | 2022 | 261 492,89 | 123,29 | 0,59548 | 261 492,89 | 126,99 | 0,59918 |
| | | 2023 | 265543,96 | 126,99 | 0,60649 | 265543,96 | 130,80 | 0,61030 |
| | | 2024 | 265543,96 | 130,80 | 0,61784 | 318 564,13 | 134,72 | 0,62176 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-4/э карарына
2 нче кушымта

Үзенә карата электр энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифлар территориаль челтәр оешмасы эшчәнлеген озак сроклы җайга салу параметрлары нигезендә билгеләнә торган «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2020-2024 елларга озак сроклы җайга салу параметрлары

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Контрольдәге чыгымнарның база дәрәҗәсе | Контрольдә тотыларга тиешле чыгымнарның нәтиҗәлелек индексы | Активлар саны буенча контрольдәге чыгымнарның сыгылмалылык коэффициенты | Электр челтәрләре аша тапшырганда электр энергиясен югалту дәрәҗәсе, % | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача дәвамлылыгы күрсәткече | Сатыла торган товарларның (хезмәтләрнең) сыйфат дәрәҗәсе | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | Электр энергиясен тапшыру ноктасына тапшыруны туктатуның уртача ешлыгы күрсәткече | Күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфат дәрәҗәсе күрсәткече |
| | | | млн сум | % | % | % | сәгать | данә | |
| 1 | «ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте – «Челтәр компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте | 2020 | 17 852,45 | 1 | 75 | 4,50 | 0,9 | 0,04 | 1 |
| | | 2021 | Х | 1 | 75 | Х | 0,9 | 0,04 | 1 |
| | | 2022 | Х | 1 | 75 | Х | 0,9 | 0,04 | 1 |
| | | 2023 | Х | 1 | 75 | Х | 0,9 | 0,04 | 1 |
| | | 2024 | Х | 1 | 75 | Х | 0,9 | 0,04 | 1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 3-4/э карарына 3 нче кушымта

«ТранзитЭнергоМонтаж» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2020-2024 елларга кирәкле тулай кереме (югалтуларга түләүне исәпкә алмыйча)

| т/с | Татарстан Республикасында челтәр оешмасының аталышы | Ел | Югалтулар өчен түләүне исәпкә алмыйча, челтәр оешмасының ЗТТ |
|---|---|---|---|
| | | | мең сум |
| 1. | "ТранзитЭнергоМонтаж" җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | 2020 | 44 059,64 |
| | | 2021 | 44 722,69 |
| | | 2022 | 45 405,63 |
| | | 2023 | 46 109,05 |
| | | 2024 | 46 833,59 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге